

Ләмберә районы Кривозерье мәк-тәбенен рус теле һәм әдәбияты укытучысы Рима Фәрит кызы Азисова житәкчелегендә 11 сыйныф укучысы Тимур Текаревнын «Гаиләм Герое» темасын яктырткан Ботенроссия конкурсында жинеп чыккан ижади эшен тәкъдим итәбез.
Безнен илдә сугыш тарихына кагыл-маган гаилә юк. 1941 нче елнын августында минем дәv әтием-прадедушкам Хәсән Якуб улы Манёровны фронтка алганнар.      Боек Ватан сугышынын дәһшәтле сулышы ана беренче минуттан ук кагыла. 1941 нче елнын октябрендә, Украина территориясенә фронт сызыгын озеп, полкнын бер олеше алга китә алмый, ә бер отряд алга таба уза һәм немецлар басып алган территориядә чолганышта кала. Совет солдатлары әсирлеккә алына. Минем дәv әтиемне һәм анын сугыш иптәшләрен Сумск олкәсе тер-риториясендә урнашкан концлагерьга жибәрәләр. Бу вакытта концлагерь vлем лагере булмаган әле; баракларсыз гына коймаланган территория булган.
Шундый катлаулы шартларда Х.Я.Манёров куркып калмый, тоткынлыктан качарга уйлый, әмма омтылышы унышсыз була. Шуна 1942 нче елнын 30 нчы апрелендә ул Оранинбургтагы «Заксенхаузен» нацистлар концлагеренә Германиягә озатыла. Тоткыннарны «производство» ишегалдында, анда минем дәv әтием белән килгән кvп кенә хезмәт союҹән кешеләрне, куәтле радиоллар тавышы астында атып vтергәннәр. Кеше, концлагерьга эләккәч, кеше булудан туктый; ул vз вакытында юкка чыгарылырга тиешле әйбергә әйләнә.
Хәсән Якуб улы йорәге биредәге шартлар белән килешми һәм кабат качарга карар итә. Анын иреккә омтылышы Ватанга чиксез тугърылыгын, vлем куркы-нычы минутларында ныклыгын һәм батырлыгын саклап калуы белән данлык лы. Фашистлар лагерыннан качу авыр һәм куркыныч эш булган: кvпләр качарга омтылган, тик кайбер торкемнәргә генә иреккә чыгарга насыйп булган. Кызганычка каршы, Х.Я.Манёровнын чираттагы качуы да унышсыз булган.
Дәv әтиемнен качарга омтылуы очен аны атып vтерергә тиеш булганнар, тик башта корыч таяклар белән нык кыйнаганнар һәм тагы да  ябыккан, жазаланган туганымны карцерга vлергә дип ташлаганнар. Каравылчыларнын берсе, бәхетенә каршы, тумышы белән Мордовиядән булган икән. Ул якташын кызганып, яшерен ашарга ташыган ана; һәрвакыт дәv әтиемнен чәйнигына су белән кишер, чогендер яки бәрәнге салып биргән. Шунын аркасында гына ул исән кала алган.
...Хәсән дәv әтиемне атарга тиешле кон житкән. Ул ничек vткән сон дип сорарсыз? Әсирләрне сафка тозгәннәр, ә тозелеш дежурные – кизv торучы, әсир солдат янына килеп, анын тоймәсеннән тарта икән: әгәр дә хәрби әсир сафта тора алмаса (гадәттә сафта тора алмаганнар), аны жәзага алып барганнар. Шулай сафтагы сонгы әсиргә кадәр vткән кизv торучы. Хәлсезләнгән Хәсән Якуб улынын (шушы вакытта Тимурнын дәv әтисенә 35 яшь булмаса да, аны чал чәчле карт дип әйтергә булган) тоймәсеннән

тартканда, аны ике яктан иптәшләре жилкәләрен жилкәгә куеп «тоталар». Шулай итеп дуслары vлемнән тартып ала дәv әтием Хәсән Якуб улын. Тик качу турындагы уй аны һаман да ташламый…
Лагерь - ул жәһәннәм, ул vлем, әмма да дәv әтием бу зур тәмугта исән кала. Kvрәсен, аны ойдәгеләре әтисенен кайтуына ышанып коткәнгә, гаиләне саклаучы фәрештә саклаганга исән кала. Шулай, бераздан, тоткыннарнын хыялы тормышка аша. Мондый хәл булган: англо-американылылар самолетлары конц лагерь территориясен ата башлаган-нар. Бу вакыйга унаеннан барлыкка килгән хаос дәv әтиемә һәм тагын берничә солдатка качарга момкинлек биргән. Алар арасында берсе француз милләтле кеше булган. Качып озак йоргәннән сон, алар Франциягә килеп житәләр. Анда Хәсән Якубович французлар Каршылыгы - Сопротивление хәрәкәте сафына керә. 1944 нче елнын июленнән октябрь аена кадәр ул французлар партизаннары отрядында була. Боек Ватан сугышы вакытында Франциядә элеккеге Совет хәрби әсирләреннән 40 ка якын партизан отряды булган. Кешеләр бирешмәгән, качып калмаган, ә Гитлерга каршы сугышкан, фашизмга каршы корәштә батырлык vрнәге булып торганнар.
Хәсән Якуб улы Манёров партизан отрядында актив эшчәнлеге, сугыш вакытында kvрсәткән батырлыгы очен француз орденнары һәм медальләре белән бvләкләнгән. Анын язмышы искиткеч. Геройнын характеры нык. Ватанны шулкадәр нык яратуы һәм дошманны kvрә алмаслыгы озак сугыш айлары дәвамында хәтта Франциядәге партизаннар отряды составында корәштерә аны! Сугыштан сон да язмыш сыный аны. НКВД тикшерvен vтәр очен Хәсән Якуб улына нинди ихтыяр коче һәм сабырлык кирәк булган! Герой дәv әтием тормыш сынауларын да vтә алган: әсир дә, чиксез тикшерvләр дә, ин моһиме, сугышны да. Х.Я.Манёров тулы тормыш белән яши; kvпсанлы егылу һәм kvпсанлы аяк остенә торып басулар vтә, Боек Ватан сугышынын ачысын һәм Жинvнен татлы тәмен сынап карарга туры килә ана.
Бу гади, әмма бик чыдам, сабыр һәм батыр кеше турында тарих: ул - гаиләмнен горурлыгы булган әтиебез, бабабыз, дәv әтиебез. Без нәкъ менә шундый кешеләр белән горурланырга, алардан vрнәк алырга һәм аларнын батырлыкларын онытмаска тиеш дип уйлыйм.

**Н.ХӘЛИЛ тәржемәсе**